КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 сентябрь г.Казань № 1127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында» 2023 ел, 18 апрель, 494 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында» 2023 ел, 18 апрель, 494 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 4 август, 943 нче; 2023 ел, 8 сентябрь, 1113 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2 488 826 065,68» саннарын «3 230 000 000,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 апрель, 494 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 14 сентябрь, 1127 нче
карары редакциясендә)

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы»
акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасын бүлү

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, сум (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) |
|---|---|---|
| 1. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы КФК. 5 нче, 6 нчы, 7 нче корпус» | 1 152 505 434,97 |
| 2. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 13 нче корпус, Композитлар» | 2 077 494 565,03 |
| Барлыгы | | 3 230 000 000,0 |

_______________________________________